# Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы «Иске Кади авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге гражданнары җыены карары

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Иске Кади авыл җирлеге составына керүче Иске Кади, Тукай бистәсе, Светлогорский бистәсе, Якты Тау авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

08 ноябрь 2019 ел № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлегенең Иске Кади авылы, Тукай бистәсе, Светлогорский бистәсе, Якты Тау авылы торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

2020 елда Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертергә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан, 90 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге кешеләрдән тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

Алынган чараларны җибәрергә:

- Иске Кади, Светлогорск, Тукай, Якты Тау торак пунктларында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу.
- Иске Кади, Светлогорск, Тукай, Якты Тау торак пунктларында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, хезмәт күрсәтү (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәтләр өчен түләү), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнары.
- Су белән тәэмин итүнең урам челтәрен һәм суүткәргеч манараларын төзү, реконструкцияләү һәм ремонтлау (артезиан скважинасы территориясенең санитар-саклау зонасын төзекләндерү, коймаларны ремонтлау һәм буяу, су башнясын буяу, павильонны тышлау, каты өслекле юл урнаштыру, җир участокларын рәсмиләштерү, проект-смета документациясе өчен түләү), Тукай

һәм Светлогорский торак пунктында, әлеге эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар (хезмәтләр) сатып алу.
- Иске Кади торак пунктындагы урам юл челтәрендә чокырларны ямау, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алу.
- Иске Кади авылы зиратлары территорияләрен төзекләндерү, иске агачларны чыгару, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу.
- Иске Кади, Якты Тау, Тукай һәм Светлогорский торак пунктларында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (янгын вакытында хәбәр итү системасын сатып алу һәм урнаштыру, сулыкларның һәм янгын гидрантларының күрсәткечләрен сатып алу һәм урнаштыру, янгын сүндерү өчен кирәкле җиһазлар сатып алу, янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру, ягулык-майлау материаллары, янгын сүндерү машинасы өчен запас частьләр сатып алу, хезмәтләр өчен түләү)

Халык җыенында рәислек итүче
Иске Кади авыл җирлеге башлыгы И.С.Мөхетдинов